# Тема : Китап укып елый алганнарның күңелендә булмый каралык

( язучы Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган китап укучылар конференциясе)

**Укытучы :**

Бер-беребезгә нинди бәгырьсез без,
Хәтта кансыз- кемнән өйрәндек?
Усаллыкка, әдәпсезлекләргә
Нинди иләк аша иләндек?
Без нинди соң, нинди юл алдык,
Аерылдык җирдән, йолалардан,
Үзебездән үзебез югалдык.

- Иман, иманлы, әхлаклы булу... Халкыбыз аңына бик борынгыдан килгән төшенчәләр. Кызганычка каршы, бу сыйфатларны бүгенге көндә югалтып бетердек түгелме? Менә шундый сыйфатларны тәрбияләүдә әдәбиятның роле әйтеп бетергесез. Чөнки әдәби әсәрләр аша яхшы белән яманны, ак белән караны, дус белән дошманны аерырга өйрәнәбез. Хәзерге чор әдабияты үзенең төп вазифасын үтәр дәрәҗәдәме? Заманның әхлакый һәм фәлсәфи кыйммәтларен үзендә туплаган геройлар, кызыклы әсәрләр туамы? Бу әдәби әсәрләр кешелек туплаган рухи байлыкларны, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, нәрсә ул яман , нәрсә ул яхшы төшенчәләрен укучыга үтемле итеп җиткерә аламы?

Әхлак мәсьәләсе тормышта, әдәбиятта һәрвакыт актуаль булды һәм булып кала. Шуңа күрә әхлак темасын әсәрләре үзәгенә куймаган автор юк та. Ләкин әдипләр тарафыннан ул төрлечә сурәтләнеш таба. Галимҗан Гыйльманов бу мәсьәләгә үзенчә якын килә.

**1 нче укучы :** Галимҗан Гыйльманов 1957 елның 1 нче февралендә Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1974 елда Әсән урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Г.Гыйльманов Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Студент елларындаук мәгълүм "Әллүки" әдәби түгәрәгендә үзенең иҗади мөмкинлекләрен сыный. Бүгенге көндә Г.Гыйльманов – әдәбиятта үзен танытып өлгергән өлкән язучы. 1972 елларда матбугатта күренә башлап, өче дистә елдан артык вакыт татар әдәбиятын үзенең әсәрләре белән тулыландырып бара.

**2 нче укучы:** Г.Гыйльманов үз каләмен әдәбиятның төрле жанрларында сынап карый. Ул шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, җыр текстлары авторы да.

“Мин шагыйрь түгел. Күңелем генә шагыйрь”,- ди автор үзе турында. Ә бит булачак шагыйрь ике яшендә үк инде әнисенең такмаклап сөюенә, шигырь белән

җавап бирә торган булган. Шагыйрь Ш.Бабич белән бер авылда туып үскәнгә, шигъри җанлы булганга , картисе аны “Минем Бабичым” ,-дип сөя торган булган.

Бабич дигәннән, бу авылдаш шагыйрь мине колагымнан тартып үстерде. Үзе түгел, әлбәттә, ә аның рухы. Үзен 1919 елда ук, 24 яшендә, Башкортстанның Зилаир авылында кызылларның Смоленск полкы урыслары, тереләй күзләрен чокып, колакларын кисеп, соңыннан ат койрыгына тагып төртеп, бөтен кеше алдында мәсхәрәләп, җәзалап үтерәләр. Идеалыннан, иманыннан һәм шигыреннән ваз кичмәгән өчен шулай эшлиләр. Без, Әсән авылы балалары, бу фаҗигане бик авыр кичереп яшәдек. Шушы хәтәр тарих безне шагыйрь итте дә бугай. Шагыйрь булмасак та, күбебезнең язмышын әдәбият белән бәйләде ул. Чынлап та, Әсән урта мәктәбендә шигырь язмаган бала сирәк булгандыр. Ш.Бабич исемендәге әдәби премия дә бар иде. Шулай туры килде инде — бу бүләкнең беренче лауреаты мин булдым, -ди яза әдип.

Күп тә үтми булачак әдипнең шигырьләре район газетасында, аннан “Яшь ленинчы” (хәзерге “Сабантуй” ) газеталарында бер-бер артлы басылып чыга.Менә шул вакытта инде ул язмышын әдәбият белән бәйләргә карар кыла. Шулай итеп ул шагыйрь булып китә. Шигырьләрендә ул әни, туган ил, милләт язмышы турында яза, яшәү –үлем мәгънәләре турында уйлана.

**Шигырь.......**

**3 нче укучы :** Г.Гыйльмановның  проза жанрындагы әсәрләре тупланган беренче китабы «Тозлы яңгыр» исемле. Бу китапта повесть, хикәя, нәсерләр тупланган.. Китаптагы әсәрләрдәге вакыйгалар  тормышчанлыгы, эчке рухи кискенлеге һәм авылга, табигатькә тугрылыгы белән укучылар күңелендә якын. Аның геройлары — гади җир кешеләре. Явачак яңгырны да Җаны-тәне белән тоеп яшәүче Ак бабайлар, бүгенге рәхимсез тормышта алган беренче күңел яраларына дәва эзләүче Саматлар, Миләүшәләр, бөтен йөрәк җылысын, күңел сафлыгын кошларга биргән Булатлар хакында ул. Автор халыкта сәер җаннар буларак телгә кергән кешеләрнең язмышларына, күңелләренә тирән төшенеп, аларның бай, матур омтылышлы рухиятен ачып бирә алган. Бу геройларны аңлау өчен китапның үзен уку кирәктер. Хәер, безнең укучыларыбыз әлеге бәхеткә иреште дә.

**“Төсләр турында баллада”  1 укучы  кыскача эчтәлеге белән таныштыра.**

**4 нче укучы:** Язучы Г.Гыйльмановның иҗатында кешенең эчке кичерешләрен, кешелеклелек сыйфатларын сурәтләүнең матур үрнәкләре бар. Ул үзенең әсәрләрендә хыял һәм чынбарлык арасындагы чикләрне юып ташлый,кискен интригага, сергә корылган вакыйгалар тәкъдим итә. Әдипнең геройлары беренче карашка сәер кешеләр, әмма алар үзләренең ихлас һәм игелекле булулары,үз язмышларына үзләре хуҗа булырга омтылулары,иманлы кеше булулары  белән хәтердә калалар.

**“Язмышның туган көне” әсәре турында белән таныштыру.**

**5 нче укытучы** : Кеше өчен иң затлы, бөек хис-яратуның серен әле тулысынча аңлата алучы булганы юк. “Мәхәббәт кешене кеше иткән нәрсә” булуына, аннан башка чын мәгънәсендә кешелеклелек, игелеклелек, башкаларны хөрмәт итүче, күңел нечкәлекләренә ия, назлы шәхес була алмавына әдәби әсәрләр укып, үз тәҗрибәбездән чыгып та әледән-әле ышанабыз. Ә менә Г. Гыйльмановның “Китек ай” әсәренең төп герое Гөлнарага килгән мәхәббәт чын мәхәббәт була аламы? Күз карасы кебек карап үстергән әти-әнисен рәнҗетүе, мәхәббәт җимеше булган баланы ташлап китүенә алда әйтеп үтелгән олы хис сәбәп буламы? Әсәрне укыганнан соң менә шушындый сораулар туа.

**Миңа бигрәк тә авторның “Китек ай” хикәясе ошады. (Әсәр белән таныштыру)**

**6 нчы укучы:** Әйе, шәфкать барчабызга да кирәк. Беркем дә үз аеның китек булуын теләми. Гөлнарага килсәк, анда татар хатын-кызына хас бала җанлылык, җаваплылык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар бөтенләй үк әле бетмәгән. Соң булса да ялгышлык эшләгәнен аңлый. Әти-әнисенә язган хатында болай ди: “Мин сезнең каршыгызда нык гаепле. Мин Ходай Тәгалә каршында да зур гөнаһлы. Ул гөнаһны гомерем буе юып бетерә алмасымны да беләм. Әмма сезнең мәрхәмәтегез, мәхәббәтегез аны бераз җиңеләйтер кебек”[5]. Әниләре янына кайткач, кайгы-хәсрәтләр алып килгән өчен гафу үтенә, ә балага кайгыртучан, назлы әнигә әверелә. Дөньяда язмыш тарафыннан кыерсытылган, күңелләре китек балалар да бар. Автор алар язмышына да битараф кала алмый. “Ясминә ятим түгел “ хикәясе нәкъ язмыш тарафыннан рәнҗетелгән балалар турында.
**“Ясминә ятим түгел “ хикәясе белән таныштыру.**

**7 нче укучы:** Бер үк вакытта Г. Гыйльманов балалар драматургиясендә дә иҗади уңышларга ирешә: халык театрлары, мәктәп драма түгәрәкләре, театр студияләре тарафыннан куелган күп кенә сәхнәлекләрен яза, ә аның «Кыш бабайда сер бар», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Миңа дус кирәк!» пьесалары буенча телефильмнар эшләнгән. Балалар сәхнәсе өчен иҗат ителгән әсәрләрендә драматург татар халкының мифологик мирасыннан, фольклордан алынган образларны яратып куллана. Әдип олылар өчен язган «Бала — бәгырь ите» исемле психологик драма авторы буларак та билгеле. Язучының әсәрләрендә убырлы карчык, шүрәлеләр, албастылар явыз итеп түгел, ярдәмчел, мәрхәмәтле, явызлыкка каршы көрәшүче итеп күрсәтелә.

**8 нче укучы:** Г. Гыйльманов озак еллар дәвамында татар халкының борынгы мифларын, риваять-легендаларын, им-томнарын, юрамышларын барлау һәм җыю, ияләр-рухлар дөньясын, тәңречелек тәгълиматын өйрәнү юлында гыйльми эзләнү-

ләрен дәвам иттерә. **1996** һәм**1998** елларда басылып чыккан «Татар мифлары» — биш том итеп уйланылган шул җыелманың тәүге ике китабын тәшкил итә.

**Укытучы:** Г.Гыйльманов – бүгенге татар әдәбиятында иң күп иҗат итүче язучыларның берсе. Аның әсәрләрен укучылар яратып укыйлар. Чөнки аларда иман, әдәп-әхлак темалары яктыртыла. Ә әхлаклы , иманлы кеше беркайчан да начарлык эшләргә сәләтле түгел. Татар халкында “Китап укып елый алганнарның күңелендә булмый каралык” дигән мәкаль бар. Мин сезнең күбрәк китап укуыгызны иманлы кешеләр булуыгызны тели.